



КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# ВЕЛОСИПЕД АЛДЫК – гарантиясе бар, тормозы юк

*«Улыма велосипед сатып алдым – җәйге каникулларга көтеп алган бүләк иде ул. Тик шатлыгы озакка бармады: ике атна үткәндерме, җитешсезлекләре ачыкланды – велосипедның тормозы начар эшли, эләгеп-туктап кала. Әгәр гарантия срогы чыкмаган икән, сыйфатсыз товар өчен сатып алучыдан акчамны кире кайтаруын таләп итә аламмы?»*

**В.Закиров**

**ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге җитәкчесе Розалия Арсланова җавап бирә:**

– Әйе, таләп итә аласыз. Таможня берлегенең «Балалар һәм яшүсмерләр өчен билгеләнгән продукциянең куркынычсызлыгы турында» техник регламенты (7 статьяның 2 пункты) буенча, велосипедның тормоз системасы төзек эшләргә, эләгеп-туктап калырга тиеш түгел. Кулланучы товарда кимчелекләр ачыкласа (әгәр сатучы белән бу хакта алдан сөйләшенмәгән булса), аның өчен түләнгән акчаларны кире кайтаруны һәм сыйфатсыз товар аркасында күргән чыгымнарны тулысынча каплауны таләп итәргә хокуклы.

Сатучы (җитештерүче) товарны кулланучыга тапшырганнан соң аны файдалану, саклау яки транспортлау кагыйдәләре бозылуын, өченче затларның гамәлләрен яки каршы тора алмаслык көчләр тәэсирен исбатлый алмаса, гарантия срогы билгеләнгән товардагы кимчелекләр өчен җавап бирә.

Кулланучылар хокукын яклау турындагы законның 18 статьясы 5 пункты нигезендә, сатучы сыйфаты тиешле дәрәҗәдә булмаган товарны кире кабул итәргә һәм кирәк икән, сатып алучы катнашында аны тикшертергә тиеш. Товарның кимчелекләре сәбәбе бәхәс уяткан очракта, экспертиза сатучы хисабына ясала. Әгәр сатып алучы тикшерү нәтиҗәләре белән риза булмаса, экспертиза бәяләмәсенә суд тәртибендә шикаять бирә ала. Кулланучының товар өчен түләнгән сумманы кире кайтару, шулай ук сыйфатсыз товар сату сәбәпле күргән чыгымнарын каплау турындагы таләпләре сатучы (җитештерүче) тарафыннан әлеге таләп куелганнан соң ун көн эчендә канәгатьләндерелергә тиеш.



**ИГЪТИБАР**

*Еш кына сатучы товарны алмаштырудан яки акчаларны кире кайтарудан баш тартып, сыйфатсыз товарны ремонтларга тәкъдим итә. Әмма сатып алучыга компенсациянең башка ысулы уңайлырак икән, ремонтланган товарны алу мәҗбүри түгел.*

# «ӘБЕКӘЙ» ТОРТЫ

**Үзе йомшак, үзе баллы – әбиләр дә, оныклар да ярата торган торт.**

Гөлүзә ВАСИЛОВА

Тәмле атна



Г.Василова фотосы

Хәзер кибетләрдә тәкъдим ителә торган «Әбекәй» тортын күпләр ярата. Аны өйдә үзегез дә пешерә аласыз.

**Камыр өчен кирәк:** *7 йомырка, 1 стакан шикәр комы, 1 кап ванилин, 1 кап камыр көпшәкләндергеч, 0,5 стакан үсемлек мае, чама белән он.*

Коймак камыры кебек булырлык итеп он салып камыр ясарга һәм мичтә корж пешерергә.

**Крем өчен кирәк:** *1 банка куертылган сөт, 500 грамм кибет каймагы.*

Коржлар пешеп чыккач, араларына крем ягарга һәм салкынга куярга.

Чәйләрегез тәмле булсын!

АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Татар–информ» мәгълүмат агентлыгында әзерләнде.

Генераль директор – Шамил Мөхәммәт улы Садыйков.
Баш редактор – Рәмис Нурмөхәммәт улы Латыйпов.
Шеф–редактор – Алсу Исмәгыйлева.
Җаваплы редактор – Лилия Гаделшина.
Дизайн–верстка – Светлана Щеглова.
Корректор – Раис Габдуллин.

Тел.: (843) 222–09–83 (1304; 1414)
Редакция һәм нәшир адресы:
420066, Казан ш., Декабристлар ур., 2нче йорт.
Эл.адрес: info@tatar–inform.tatar
Реклама хезмәте телефоны: (843) 570–31–07

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсендә Федераль күзәтчелек хезмәтенең (РОСКОМНАДЗОР) Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2014 елның 9 гыйнварында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы: ПИ №ТУ16–01140
Басмага бирү вакыты: 12 июнь 2019,
график буенча – 24.00, гамәлдә – 24.00

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ

Нәшир адресы:
420097, Казан ш., Академия ур., 2
**Басылу урыны:**
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Идел–Пресс» полиграфия–нәшрият комплексы.,
Казан ш., Декабристлар ур., 2
Тираж – 50 766 экз.

**Гомуми тираж: 68 174 экз.**

Редакция фикере автор фикере белән туры килмәскә мөмкин. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама игъланнарының дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.

© Язмаларны күчереп бастыру фәкать редакция рөхсәте белән генә башкарылырга тиеш. Газета атна саен чыга. Бәясе ирекле.

*«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла*

16+